
шалтыратып, түгәрәк буйлап йөри. Көй туктаганда, кыңгырауныбер баланың артына идәнгә куя. Барлык балалар да борылып карыйлар. Артына кыңгырау куелган бала йөгереп китә. Каршы якка кыңгырау куючы бала йөгереп китә. Кем беренче килеп җитә, шул, кыңгырауны алып, уенны дәвам итә.

**Әбәк**

Уен бер төркем балалар арасында уйнала. Арадан бер бала икенче баланың аркасына, йомшак кына итеп, әбәк, дип, тиз генә суга да үзе бер якка кача. Сугылган бала, икенче берәүне куып җитеп, әбәкне кайтарырга тиеш

***Бергәләп өйрәник***



# ***Кыш***

***Әти-әниләр өчен к ярдәмлек***

***(4-5 яшь)***

***Җырлар, юаткычлар, эндәшләр***

Утыр, балам, ашарга,
Түгеп-чәчеп ашама.
Матур утыр табында,
Алдыңа күл ясама
Ипи валчыгыңны койма,
Аяк астына ташлама

Әй чулпысы, чулпысы,
Бигрәк матур тәңкәсе.
Аккош микән, былбыл микән.
Моны тапкан әнкәсе.

***Табышмаклар***

Тәңкә карлар сипкән,

Җирне ап-ак иткән,

Чыршы, каен, имән

Кардан чикмән кигән.

Бу кайчак? (Кыш)

Колак, борынны уып,

Өеңә кертә куып (Салкын)

Ишегалдында таш була,

Өйгә керсә, су була (Боз)

Шигырьләр

***Кыш***

Уянып бүген иртән
Карасам тәрәзәгә,
Ак сакаллы Кыш бабай
Кар алып килгән безгә.

Әйдәгез, тауга барыйк,
Чанада шуып калыйк.
Бер тузан юк, саф һава,
Җиргә ап-ак кар ява.

Җәвад Тәрҗеманов

Чанада да шуабыз,
Чаңгыда да шуабыз.
Тимераякта очабыз,
Чыңлап тора шома боз.

Тауларга да барабыз, Кырларга да чыгабыз.
Кар-буран дип тормыйбыз,
Шуабыз да шуабыз.

Нәҗип Мадьяров

**Үстерешле уеннар**

**Матур уен**

Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бал уртага баса

Син уртада без кырыйда
Әйләнәбез түгәрәк.
Уеныбыз матур булсын,
Күңел ачыйк бергәләп.

*Балалар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр,*

Таянабыз билләргә,
Тотынабыз биергә.
Тыпыр-тыпыр тыпырдатып
Әйләнәбез без бергә.

*туктап, түгәрәк уртасына борылалар, кулларын билгә куялар, аякларын тыпырдаталар, парлашып әйләнәләр.*

**Хәрәкәтле уеннар**

***Кыңгырау***

Балалар, түгәрәк ясап, идәнгә тезләнәләр. Бер бала, матур көй астында кыңгырауны